ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау тиемер юл станциясе поселогы, Совет ур., 13

СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР**
**9 октябрь 2021 ел**

**РЕШЕНИЕ**
**№ 31**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге башлыгы һәм депутаты Р.Г. Кәлимуллинын вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 36 статьясындагы 6 өлешенең 2 пункты, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 24 статьясындагы 8 өлеше, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Уставының 48 статьясындагы 1 өлешенең 2 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Советы,

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Калимуллин Рөстәм Галиулла улының шәхси гаризасы буенча, Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге башлыгы вазифасыннан отставкасын кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советы депутаты Кәлимуллин Рөстәм Галиулла улының 2021 елның 9 октябреннән, аны «Бердәм Россия» Бөтенроссия сәяси партиясе тарафыннан тәкъдим ителгән кандидатларның федераль исемлеге составында VIII чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты итеп сайлануына бәйле рәвештә, вакытыннан алда вәкаләтләрен туктатырга.

3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау тимер юл станциясе поселыгы, Совет урамы, 13 нче йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча Һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында»: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Красносельский авыл җирлеге
башлыгы урынбасары Р.Р. Никитенко